**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**10 ноябрь 2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципилары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Башлыгының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"27.10.2025 ел, № 2 карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Тымытык авыл җирлеге Күк-Тәкә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә, көндезге формада белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

1) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Күк-Тәкә авылының «Ачы» чишмәсен киртәләү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62 нче йорт; Күк-Тәкә авылы, Ленин ур., 40 нчы йорт адреслары буенча Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге башлыгы Л.Р.Мостафина